**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№6006**
**10.10.2018**

«Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы гражданнар хәле актларын теркәү идарәсе» муниципаль казна учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 17 маддәсенең 1 бүлегендәге 4 пункт, шәһәр Уставының 41 маддәсе, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 нче карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәт күрсәтүләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакындагы нигезнамәнең 5 пункты, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 нче карары белән расланган Муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турындагы нигезнамә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы гражданнар хәле актларын теркәү идарәсе» муниципаль казна учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2018 елның 10 октябрендәге
6006 нчы карарына
кушымта

«Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
Башкарма комитеты карамагындагы гражданнар хәле актларын теркәү идарәсе»
муниципаль казна учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә
тарифлар

| Т/с | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Хезмәтнең бәясе |
|---|---|---|---|
| 1. Көнбатыш зал хезмәтләре | | | 4 100,00 |
| 1 | Тантаналы церемония оештыру һәм үткәрү | 1 церемония | 1 950,00 |
| 2 | Музыка белән алып бару (камера ансамбле) | 1 церемония | 1 200,00 |
| 3 | Котлау залы хезмәтләре | 1 церемония | 950,00 |
| 2. Көнчыгыш зал хезмәтләре | | | 2 850,00 |
| 1 | Тантаналы церемония оештыру һәм үткәрү | 1 церемония | 1 950,00 |
| 2 | Музыка белән алып бару (соло) | 1 церемония | 900,00 |
| 3. Көньяк зал хезмәтләре | | | 1 950,00 |
| 1 | Тантаналы церемония оештыру һәм үткәрү | 1 церемония | 1 950,00 |
| 4. Церемониянең тантаналылыгын тәэмин итү буенча өстәмә хезмәтләр | | | |
| 1 | Музыка белән алып бару (вокал) | 1 церемония | 650,00 |
| 2 | Интерьерларны фото-видеога төшү өчен бирү | 1 пар | 200,00 |
| 3 | Церемонияне алып баручы хезмәте күрсәтү | 1 церемония | 500,00 |
| 4 | Гаиләләргә барып церемония үткәрү өчен яңа йолалар әзерләү | 1 церемония | 5 000,00 |
| 5 | Күгәрченнәр очыру йоласы | 1 пар | 650,00 |
| 6 | Роза таҗларыннан салют | 1 церемония | 200,00 |
| 7 | Гаилә дипломы тапшыру йоласы | 1 церемония | 400,00 |
| 8 | Яшь гаиләгә (яки яңа туган балага) беренче документ тапшыру йоласы | «А» тибындагы тышлык | 150,00 |
| | | «В» тибындагы тышлык | 300,00 |
| | | «С» тибындагы тышлык | 400,00 |
| 9 | «Йозак – чиксез мәхәббәт символы» йоласы | 1 церемония | 350,00 |
| 10 | Тантаналар оештыру буенча хезмәтләрнең мәгълүматлар банкына мәгълүмат кертү | 1 айга / 1 төр хезмәт | 1 500,00 |
| 11 | Фото-видеога төшерү хезмәте (DVD-диск һәм 10 данәдән торган фотосурәтләр комплекты биреп) | 1 хезмәт | 2 050,00 |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе — Г.К. Әхмәтова